**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«12» ноября 2024 ел** **№ 142**

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 29 мартындагы 44 номерлы «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 29 мартындагы 44 номерлы «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү» Муниципаль программасына:

А) 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү» муниципаль программасында кулланыла торган терминнар «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законда күрсәтелгән мәгънәдә кулланыла;

Б) түбәндәге эчтәлекле 1.1.1 пункт белән тулыландырырга:

«1.1.1. Текстта түбәндәге кыскартылмалар кулланыла:

КУЭ - кече һәм урта эшкуарлык;

КУЭС - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары;

КЭ - кече эшкуарлык;

УЭ - урта эшкуарлык;

Иҗтимагый совет - Кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү мәсьәләләре буенча Иҗтимагый совет;

Программа - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү;

ИЭ - эшкуарлык эшчәнлеген юридик зат төземичә гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуарлар;

КФХ, К(Ф)Х - крестьян (фермер) хуҗалыклары;

ШЯХ - шәхси ярдәмче хуҗалыклар;

ТТП - тулай территориаль продукт;

ММЧ -массакүләм мәгълүмат чаралары;

АПК - агросәнәгать комплексы;

ТСП - «Теләче» сәнәгать паркы;

АХКК - авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы;

АХҖ- авыл хуҗалыгы җирләре;

Инвестиция Советы - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башлыгы каршындагы Иҗтимагый инвестиция Советы;

ТМР - Теләче муниципаль районы;

ҖҮИО, ҖҮИ - җирле үзидарә органнары;

ИК - Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты;

ТҮБ - Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге;

ХМҮ - "Татарстан Республикасы халкы мәшгульлеге үзәге" дәүләт казна учреждениесе;

СП - авыл җирлеге;

МһҖМП - Теләче муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы;

МХП - муниципаль хосусый партнерлык;

АХһАТИ - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин